Өченче чакырылыш Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советының утыз беренче утырышы

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советы
карары

26 март, 2020 ел № 254

2020-2022 елларга Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы муниципаль милекне хосусыйлаштыруның фараз планы (программасы) турында

2001 елның 21 декабрендә кабул ителгән 178-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында», 2003 елның 6 октябрендә кабул ителгән 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәләрне оештыруның гомуми принциплары турында», 2006 елның 26 июлендәге 135-ФЗ номерлы «Конкуренцияне яклау турында» гы Федераль законнары, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы уставы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының муниципаль милекләрен хосусыйлаштыру тәртибе турындагы нигезләмәсе нигезендә **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль район Советы карар кабул итте:**

1. 2020-2022 елларга муниципаль милекне хосусыйлаштыруның фараз планынын (программасын) раcларга (кушымта).
2. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы 2020-2022 елларга Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының фараз планын (программасын) билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашыруны тәэмин итәргә.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
4. Әлеге карар рәсми бастырылган көннән көченә керә.

Питрәч муниципаль районы башлыгы И.М. Кашапов.

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль район
Советы карарына кушымта
«26» март, 2020 ел № 254

# 2020-2022 елларга муниципаль милекне хосусыйлаштыруның фараз планы (программасы)

## 1. Гомуми нигезләмә

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының 2020-2022 елларга муниципаль милекне хосусыйлаштыруның фараз планы (программасы) 2001 елның 21 декабрендә кабул ителгән 178-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында», 2003 елның 6 октябрендә кабул ителгән 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәләрне оештыруның гомуми принциплары турында» гы Федераль законнары, «Конкуренцияне яклау турында» 2006 елның 26 июлендәге 135-ФЗ номерлы Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе турында нигезләмәсе белән (Питрәч муниципаль районы Советының 2017 елның 29 декабрендәге 124 номерлы, 2019 елның 5 декабрендәге 239 номерлы карары белән расланган үзгәрешләр белән).

Хосусыйлаштыру объектларын сатуның башлангыч бәясе «Россия Федерациясенең бәяләү эшчәнлеге турында» 1998 елның 29 июлендәге 135-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә билгеләнгән базар бәясе нигезендә билгеләнә.

Питрәч муниципаль районы муниципаль милкен хосусыйлаштыруның төп бурычы булып муниципаль милекне хосусыйлаштыру хисабына Питрәч муниципаль районы җирле үзидарә органнарының функцияләрен (вәкаләтләрен) һәм бурычларын тәэмин итү өчен файдаланылмый торган һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен билгеләнмәгән муниципаль милек структурасын оптимальләштерү тора.

Хосусыйлаштыруның төп максатлары түбәндәгеләр:

- тулаем Питрәч муниципаль районы икътисадының һәм аерым хуҗалык субъектлары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру;
- муниципаль милек объектларын тотуга җирле бюджет чыгымнарын киметү;
- Питрәч муниципаль районы икътисадын һәм аның инфраструктурасын үстерү өчен инвестиция чараларын җәлеп итү;
- муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштырудан акчалар исәбеннән җирле бюджетны тулыландыру;
- җәлеп ителгән акчалар, шулай ук муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштырудан алынган акчалар исәбеннән муниципаль ресурсларны торгызу;
- Питрәч муниципаль районы территориясендә эшкуарлык эшчәнлеген үстерүгә һәм бизнесны озак сроклы үстерүгә һәм яңа эш урыннары булдыруга юнәлтелгән нәтиҗәле милекчеләр формалаштыруга ярдәм итү.

2020-2020 елларга муниципаль милекне хосусыйлаштыруның прогноз планы (программасы) гамәлдә булу срогы дәвамында аңа Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карарлары нигезендә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертелә ала.

Ел дәвамында хосусыйлаштырылмаган муниципаль милек объектлары киләсе елга прогноз планына кертелә.

## 2. Хосусыйлаштыруга тиеш булган муниципаль милек

| № п/п | Урнашкан урыны | Мөлкәтнең исеме | Мәйдан, кв.м. | Хосусыйлаштыруның планлаштырылган вакыты |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Татарстан Республикасы, Питрәч районы, Шәле ав., Хәйруллин ур., 38 й. | Билгеләү: торак булмаган бина; исеме: котельная | 136 | 2–4 квартал 2020 ел |
| 2 | Татарстан Республикасы, Питрәч районы, Татар Казысы авыл җирлеге, Татар Казысы авылы, Централь ур., 4 й. | Билгеләү: торак булмаган бина; исеме: балалар бакчасы 16:33:000000:1857 | 155,1 | 2–4 квартал 2020 ел |